ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүматны саклау хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 530-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында законнарны гамәлгә ашыру өчен кирәкле норматив хокукый актларны тиз арада кабул итү кирәклеге хакында Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүматны саклау хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 530-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында законнарны гамәлгә ашыру өчен кирәкле норматив хокукый актларны тиз арада кабул итү кирәклеге хакында Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мөрәҗәгатен кабул итәргә һәм аны Россия Федерациясе Хөкүмәтенә җибәрергә.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарына җибәрергә.

3. Әлеге карарны республика массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2021 елның 11 июне
№ 975-VI ДС

**«Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүматны саклау хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 530-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында законнарны гамәлгә ашыру өчен кирәкле норматив хокукый актларны тиз арада кабул итү кирәклеге хакында Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы**

**МӨРӘҖӘГАТЕ**

Хөрмәтле Михаил Владимирович!

2020 елның 30 декабрендә Россия Федерациясе Президенты В.В. Путин тарафыннан «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүматны саклау хакында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль законга социаль челтәрләрдә мәгълүмат тарату үзенчәлекләрен, шул исәптән Интернет челтәрендәге социаль челтәрләрдә хокукка каршы мәгълүмат таратуга юл куймауның хокукый һәм оештыру нигезләрен билгели торган яңа $10^6$ статья өстәү турындагы 530-ФЗ номерлы Федераль законга кул куелды.

Федераль законның 2021 елның 1 февраленнән үз көченә кергән күрсәтелгән нормалары гомумфайдаланудагы мәгълүмат кырын Россия Федерациясе законнары белән тыелган мәгълүматтан чистарту бурычын хәл итүне максат итә, хокукка каршы мәгълүматны социаль челтәрләрдә таратуны башлангыч чорында, шул ук вакытта тикшереп торучы органнарның санын арттырмыйча, кисәтергә, шулай ук мондый мәгълүмат ресурсларын блокировкалауны кулланмаска мөмкинлек бирә.

Яңа норматив җайга салуда куелган максатларга ирешү өчен Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә федераль күзәтчелек хезмәте (Роскомкүзәтчелек) дәрәҗәсендә законнарны гамәлгә ашыру өчен кирәкле бер төркем актларны, шул исәптән социаль челтәргә мониторинг ясау барышында яисә мөрәҗәгать карау нәтиҗәләре буенча Роскомкүзәтчелек ачыклаган мәгълүматны аның тарафыннан карау тәртибен, Роскомкүзәтчелекнең вәкаләтле дәүләт органнары һәм башка органнар белән хезмәттәшлек итү тәртибен кабул итү таләп ителә.

Ләкин мондый актлар әле хәзергә кадәр кабул ителмәгән, шул сәбәпле Федераль закон нормалары гамәлгә ашырыла алмый.

Федераль законны тулы күләмендә гамәлгә ашыру мөмкинлеге булмау асылда аның кыйммәтен һәм әһәмиятен киметеп кенә калмый, ә тискәре тәҗрибәнең сакланып калуына китерә, шул рәвешле тиешле интернет-сайтлар, социаль челтәрләр тыелган һәм деструктив мәгълүматны тарату мәйданы булып калалар. Аларда хәтта җинаять гамәлләрен, шул исәптән балаларга һәм яшүсмерләргә карата башкарылганнарын, мактау яки аклау белән сугарылган астыртын бәя дә бирелә.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, Сездән, хөрмәтле Михаил Владимирович, «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүматны саклау хакында» 149-ФЗ номерлы Федераль законның $10^6$ статьясын гамәлгә ашыру тәртибен билгели торган законнарны гамәлгә ашыру өчен кирәкле норматив хокукый актларның тиз арада кабул ителүен тәэмин итүегезне үтенәбез.

Күрсәтелгән норматив хокукый актларны кабул итү Интернет челтәрендәге социаль челтәрләрдә таратыла торган мәгълүматның тискәре йогынтысын чикләргә мөмкинлек бирәчәк.

---